**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6435**
**30.11.2020**

Шәһәр оешмалары арасында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары буенча эшләрне иң яхшы оештыруга шәһәр смотр-конкурсы турында

Башкарма комитетның 2019 елның 21 октябрендәге 5365 номерлы карары белән расланган «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәрендә хезмәтне саклау һәм аның шартларын яхшырту» муниципаль программасы нигезендә производство травматизмы һәм һөнәргә бәйле авырулар дәрәҗәсен киметү, шәһәр оешмаларында куркынычсыз хезмәт шартлары тудыру максатында

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) шәһәр оешмалары арасында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары буенча эшләрне иң яхшы оештыруга шәһәр смотр-конкурсы (алга таба – конкурс) турында нигезләмәне 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурс үткәрү буенча комиссия составын 2 нче кушымтада каралганча.

2. Башкарма комитет карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Хезмәтне саклау буенча ел саен үткәрелә торган конкурс турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 28 октябрендәге 7341 номерлы;

2) «Башкарма комитетның 2017 елның 28 октябрендәге 7341 номерлы карары белән расланган хезмәтне саклау буенча ел саен үткәрелә торган конкурс турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 27 сентябрендәге 4918 номерлы.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы Р.М. Мингалиевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                    Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 30 ноябрендәге
6435 номерлы карарына
1 нче кушымта

Шәһәр оешмалары арасында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары буенча эшләрне иң яхшы оештыруга шәһәр смотр-конкурсы турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Хезмәтне саклауны камилләштерү, хезмәт шартларын үтәү һәм хезмәтне саклау, әлеге мәсьәләгә Яр Чаллы шәһәре территориясендә эшләүче эш бирүчеләр, профсоюзлар һәм хезмәткәрләрнең башка берләшмәләре ягыннан игътибарны көчәйтү максатында, шәһәр оешмалары арасында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары буенча эшләрне иң яхшы оештыруга шәһәр смотр-конкурсы ел саен үткәрелә.

2. Конкурсның максатлары:

1) эш урыннарында куркынычсыз эш шартларын тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итүнең мөһимлегенә җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итү;

2) хезмәтне саклау һәм хезмәт шартларын яхшырту, хезмәтне саклау системасы белән идарә итү системасын кертү буенча эшне активлаштыру һәм камилләштерү.

3. Конкурсның бурычлары:

1) эш бирүчеләрнең хезмәткәрләрне сәламәт һәм куркынычсыз хезмәт шартлары белән тәэмин итү, аларның хезмәтне саклау өлкәсендә гамәлдәге законнарда каралган бурычларны үтәү буенча эшчәнлеген активлаштыру;

2) хезмәтне саклау буенча укыту һәм инструктаж бирү, белемнәрне тикшерү системасын камилләштерү;

3) шәһәр оешмаларында хезмәтне саклау буенча алдынгы эш тәҗрибәсен өйрәнү һәм тарату.

2 бүлек. Конкурсны оештыру һәм аның шартлары

4. Конкурс оештыруны составы Башкарма комитет карары белән раслана торган конкурс үткәрү буенча комиссия (алга таба – комиссия) гамәлгә ашыра.

5. Конкурста катнашу шартлары:

1) конкурста катнашучы оешмада агымдагы елда үлем белән тәмамланган бәхетсезлек очраклары булмау;

2) ел дәвамында бәхетсезлек очраклары һәм һөнәргә бәйле авырулар саны булмау яки сизелерлек кимү;

3) хезмәтне саклау һәм хезмәт шартларын яхшырту буенча программа кабул итү һәм аны үтәү;

4) оешмада түбәндәге юнәлешләр буенча эш алып бару:

- эшләүчеләрнең хезмәт шартларын яхшырту буенча:

оешма хезмәткәрләрен индивидуаль саклану чаралары белән тәэмин итү;

технологик процессны яхшырту;

- эшләүчеләрнең санитар-көнкүреш тәэмин ителешен яхшырту:

эш урынының яктыртылуы, газлар белән пычрануы, чүпләнүе;

- хезмәтне саклауны тәэмин итү буенча:

хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәте гарантияләрен үтәү;

оешмада хезмәтне саклау хезмәтен булдыру;

5) оешмада хезмәтне саклау турында коллектив шартнамәсе бүлекләрен һәм (яки) хезмәтне саклау буенча килешүне үтәү.

6. Конкурста катнашу өчен кирәкле документлар:

1) әлеге нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендә заявка;

2) әлеге нигезләмәнең 2 нче кушымтасы нигезендә конкурста катнашучы оешмада хезмәтне саклау һәм хезмәт шартларының торышы күрсәткечләре.

## 3 бүлек. Конкурс номинацияләре

7. Конкурс җиңүчеләрен түбәндәге номинацияләр буенча билгелиләр:

1) җитештерүгә бәйле оешмалар арасында хезмәтне саклау өлкәсендә иң яхшы оешма;

2) җитештерүгә бәйле булмаган оешмалар арасында хезмәтне саклау өлкәсендә иң яхшы оешма;

3) мәгариф оешмалары арасында хезмәтне саклау өлкәсендә иң яхшы оешма;

4) сәламәтлек саклау оешмалары арасында хезмәтне саклау өлкәсендә иң яхшы оешма;

5) кече эшмәкәрлек оешмалары арасында хезмәтне саклау өлкәсендә иң яхшы оешма.

## 4 бүлек. Конкурска йомгак ясау сроклары һәм тәртибе

8. Конкурска йомгак 25 декабрьгә кадәр ясала. Оешмалар арасында номинацияләр буенча конкурс җиңүчеләре, конкурста катнашкан оешма җыйган баллар санын санау юлы белән, әлеге нигезләмәнең 3 нче кушымтасына туры китереп, Бәяләү күрсәткечләре таблицасы нигезендә комиссия тарафыннан билгеләнә.

9. Тапшырылган материаллар нигезендә комиссия конкурс җиңүчеләре турында карар кабул итә, ул комиссия рәисе яки рәис урынбасары тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

10. Конкурс материаллары катнашучыларга кире кайтарылмый һәм өченче затларга бирелми.

11. Конкурс җиңүчеләре дипломнар һәм кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнә. Җиңүчеләрне бүләкләү Бөтендөнья хезмәтне саклау көне алдыннан үткәрелә (28 апрель).

12. Конкурс йомгаклары турында мәгълүмат массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарыла һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштырыла.

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе
урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе
башлыгы вазыйфаларын башкаручы А.Ф. Бареева

Шәһәр оешмалары арасында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары буенча эшләрне иң яхшы оештыруга шәһәр смотр-конкурсы турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

Хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары буенча эшләрне
иң яхшы оештыруга шәһәр смотр-конкурсында катнашуга
заявка
(оешма бланкында тутырыла)

______________________________________________________________________________
(оешманың факттагы һәм юридик адресы, ОКВЭД, тел./факс, эл. почта)

урнашкан ______________________________________________________________,
(оешманың тулы исеме күрсәтелә)
хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары буенча эшләрне иң яхшы оештыруга смотр-конкурста катнашучы сыйфатында

_____________________________________________________________ номинациясендә
(номинация тулысынча күрсәтелә)
теркәвегезне сорыйм.

Оешманың элемтәгә керүче заты:
Фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы
Телефоны: код______ номер_________ Моб. тел. ________________

Оешма җитәкчесе ___________________________________________________________
(Ф.И.А.и., имза, дата)
М.У.

Профсоюз комитеты рәисе (вәкиллекле орган хезмәткәрләренең башка вәкаләтлесе)
______________________________________________________________________________
(Ф.И.А.и., имза, дата)

М.У.

Шәһәр оешмалары арасында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары буенча эшләрне иң яхшы оештыруга шәһәр смотр-конкурсы турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

Конкурста катнашучы оешмада хезмәтне саклау һәм хезмәт шартларының торышы күрсәткечләре

___

(оешманың тулы исеме, юридик адрес, тел/факс)

___

I. Гомуми мәгълүматлар
Милек төре ___
Эшчәнлек төре ___
Төп башкарыла торган эш төрләре ___

| № т/б | Күрсәткечләр исемлеге | Мәгълүмат лар | Баллар саны |
|---|---|---|---|
| | 1. Оешма турында гомуми мәгълүматлар | | |
| 1.1. | Хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача саны, кеше | | * |
| 1.2. | Санитар-гигиена нормаларына җавап бирми торган хезмәт шартларында эшләүчеләр: | | |
| | - кеше | | * |
| | - хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача санына карата % ларда | | |
| 1.3. | Куркынычсызлык таләпләренә җавап бирми торган җиһазларда эшләүче хезмәткәрләр саны: | | |
| | - кеше | | * |
| | - хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача санына карата % ларда | | |
| | 2. Оешмада хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары буенча эшләрне оештыруны характерлый торган күрсәткечләр | | |
| 2.1. | Оешмада хезмәтне саклау белән идарә итү системасын регламентлаштыра торган норматив документ булу (әйе (күчермәсе комиссиягә бирелә) /юк) | | |
| 2.2. | Төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләрнең һәм башка категория хезмәткәрләренең документаль рәсмиләштерелгән вәкаләтләрен, бурычларын һәм җаваплылыкларын билгеләү (әйе/юк) | | |
| 2.3. | Җитәкчеләрне һәм белгечләрне хезмәтне саклау буенча укытуга җәлеп итү, аларның гомуми санына карата % ларда | | |
| 2.4. | Хезмәткәрләрнең хезмәтне саклау буенча инструктаж үтүе, аларның гомуми санына карата % ларда | | |
| 2.5. | Хезмәтне саклау хезмәте (бүлеге, бюросы, белгече) яисә шартнамә буенча тиешле функцияләрне башкара торган заты яки оешмасы булу (әйе (саны)/юк) | | |
| | Хезмәтне саклау хезмәте турында нигезләмә булу (әйе (күчермәсе комиссиягә бирелә) /юк) | | |
| | Хезмәтне саклау хезмәте хезмәткәрләре тарафыннан бирелгән күрсәтмәләр саны | | * |
| | Күрсәтмәләрдә чагылдырылган кимчелекләрне бетерү % ы | | * |
| 2.6. | Хезмәтне саклау комитеты (комиссиясе) булу (әйе/юк) | | |
| | Хезмәтне саклау комитеты (комиссиясе) турында нигезләмә булу (әйе (күчермәсе комиссиягә бирелә) /юк) | | |
| | Үткәрелгән утырышлар һәм карап тикшерелгән мәсьәләләр саны | | * |

| № т/б | Күрсәткечләр исемлеге | Мәгълүмат лар | Баллар саны |
|---|---|---|---|
| 2.7. | Хезмәтне саклау буенча вәкаләтле (ышанычлы) затлар булу (әйе (кеше) /юк) | | |
| | Хезмәтне саклау буенча вәкаләтле (ышанычлы) затлар тарафыннан бирелгән күрсәтмәләр саны | | * |
| | Күрсәтмәләрдә чагылдырылган кимчелекләрне бетерү % ы | | * |
| 2.8. | Хезмәт шартларын яхшырту һәм сәламәтләндерү буенча чаралар планы булу (әйе (күчермәсе комиссиягә бирелә) /юк) | | |
| | Хезмәт шартларын яхшырту һәм сәламәтләндерү буенча чаралар планын үтәү % лары | | * |
| | Хезмәт шартларын яхшырту һәм сәламәтләндерү буенча чаралар планын үтәүгә тотылган чыгымнар (мең сум) | | * |
| 2.9. | Коллектив шартнамәсе (килешүе) булу (әйе (раслау датасы) /юк) | | |
| 2.10. | Коллектив шартнамәсендә (килешүендә) хезмәтне саклау буенча бүлек булу (әйе/юк) | | |
| | - планлаштырылган чараларның гомуми санына карата аның үтәлеш дәрәҗәсе, % ларда | | * |
| 2.11. | Хезмәтне саклау буенча планлы чаралар үткәрү нәтиҗәсендә хезмәт шартлары яхшыртылган хезмәткәрләр саны, кеше | | * |
| 2.12. | Елына хезмәтне саклауга тотылган чыгымнар суммасы, мең сум: | | * |
| | - 1 хезмәткәргә исәбеннән, мең сум. | | * |
| 2.13. | Продукция (эшләр, хезмәтләр) җитештерү чыгымнары суммасында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартларын яхшырту чараларына тотылган чыгымнар өлеше | | * |
| 2.14. | Сертификацияләнгән махсус өс киеме, махсус аяк киеме һәм башка индивидуаль саклану чаралары белән тәэмин ителеш, еллык ихтыяҗга карата % ларда | | |
| 2.15. | Хезмәт шартлары буенча махсус бәяләү (аттестация) үткәрелгән оешмада махсус бәяләү (эш урыннарын аттестацияләү) үткәрүнең дәрәҗәсе, оешмадагы эш урыннарының гомуми санына карата % ларда | | |
| 2.16. | Хезмәткәрләрнең медицина каравы (тикшерүләре) үтү дәрәҗәсе, әлеге карауларны үтәргә тиешле хезмәткәрләр санына карата % ларда | | |
| 2.17. | Хезмәтне саклау буенча җиһазланган кабинет (почмак(лар) булу (әйе/юк) | | |
| 2.18. | Хезмәтне саклау көннәре үткәрелде (үткәрелде (саны) /үткәрелмәде) | | |
| 3. Производство травматизмы, һөнәргә бәйле авырулар, авариялелек күрсәткечләре | | | |
| 3.1. | Производстводагы бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә зыян күрүчеләр саны, барлыгы, кеше, шул исәптән: | | * |
| | - авырлык дәрәҗәсе буенча җиңел дип саналган бәхетсезлек очракларында | | * |
| | - авыр бәхетсезлек очракларында, кеше | | * |
| | - үлем белән тәмамланган бәхетсезлек очракларында, кеше | | * |
| | - төркемле бәхетсезлек очракларында, кеше | | * |
| 3.2. | Производстводагы бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә зыян күрүчеләр саны, 1 мең эшләүчегә исәпләгәндә (ешлык коэффициенты) | | |
| 3.3. | 1 һәм аннан күбрәк эш көне дәвамында хезмәткә яраклылыкны югалтып зыян күргәннәрнең хезмәткә яраксызлык көннәре саны, 1 зыян күрүче исәбеннән (авырлык коэффициенты) | | |
| 3.4. | Беренче тапкыр һөнәргә бәйле авыру билгеләнгән затларның саны, барлыгы | | |
| 3.5. | Куркыныч производство объектларындагы авариялелек (әйе/юк) | | |
| 3.6. | Ведомстводагы автотранспортта авариялелек дәрәҗәсе, автотранспорт чаралары берәмлеге исәбеннән | | |

* - баллар тигез булганда һәм бәхәсле мәсьәләләрне хәл иткәндә комиссия тарафыннан исәпкә алына торган мәгълүматлар

Оешма җитәкчесе ________________________________________________

(Ф.И.А.и., имза, дата)

Профсоюз комитеты рәисе (вәкиллекле орган хезмәткәрләренең башка вәкаләтлесе) ________________________________________________

(Ф.И.А.и, имза, дата)

М.У.

Шәһәр оешмалары арасында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары буенча эшләрне иң яхшы оештыруга шәһәр смотр-конкурсы турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

## Оешмада хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары торышын бәяләү күрсәткечләре таблицасы

| № т/б | Күрсәткечләр | Баллар саны |
|---|---|---|
| 1. Оешма турында гомуми мәгълүматлар | | |
| 1.1. | Хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача саны, кеше | * |
| 1.2. | Санитар-гигиена нормаларына җавап бирми торган хезмәт шартларында эшләүчеләр: | |
| | - кеше | * |
| | - хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача санына карата % ларда | |
| | 15% ка кадәр | 1 |
| | 15% тан 25% ка кадәр | 0.5 |
| | 25% тан югары | 0 |
| 1.3. | Куркынычсызлык таләпләренә җавап бирми торган җиһазларда эшләүче хезмәткәрләр саны: | |
| | - кеше | * |
| | - хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача санына карата % ларда | |
| | 0,1 гә кадәр | 1 |
| | 0,1 | 0.5 |
| | 0,1 дән югары | 0 |
| 2. Оешмада хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары буенча эшләрне оештыруны характерлый торган күрсәткечләр | | |
| 2.1. | Оешмада хезмәтне саклау белән идарә итү системасын регламентлаштыра торган норматив документ булу (әйе (күчермәсе комиссиягә бирелә) /юк) | |
| | Әйе | 3 |
| | Юк | 0 |
| 2.2. | Төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләрнең һәм башка категория хезмәткәрләрнең документаль рәсмиләштерелгән вәкаләтләрен, бурычларын һәм җаваплылыкларын билгеләү (әйе/юк) | |
| | Әйе | 3 |
| | Нет | 0 |
| 2.3. | Җитәкчеләрне һәм белгечләрне хезмәтне саклау буенча укытуга җәлеп итү, аларның гомуми санына карата % ларда | |
| | 90% ка кадәр | 0 |
| | 90 % тан югары | 3 |
| 2.4. | Хезмәткәрләрнең хезмәтне саклау буенча инструктаж үтүе, аларның гомуми санына карата % ларда | |
| | 80 % ка кадәр | 0 |
| | 80 % тан югары | 3 |
| 2.5. | Хезмәтне саклау хезмәте (бүлеге, бюросы, белгече) яисә шартнамә буенча тиешле функцияләрне башкара торган заты яки оешмасы булу (әйе (саны)/юк) | |
| | Әйе | 3 |
| | Юк | 0 |

| № т/б | Күрсәткечләр | Баллар саны |
|---|---|---|
| | Хезмәтне саклау хезмәте турында нигезләмә булу (әйе (күчермәсе комиссиягә бирелә) /юк) | |
| | Әйе | 3 |
| | Юк | 0 |
| | Хезмәтне саклау хезмәте хезмәткәрләре тарафыннан бирелгән күрсәтмәләр саны | * |
| | Күрсәтмәләрдә чагылдырылган кимчелекләрне бетерүнең % лары | * |
| 2.6. | Хезмәтне саклау комитеты (комиссиясе) булу (әйе/юк) | |
| | Әйе | 3 |
| | Юк | 0 |
| | Хезмәтне саклау комитеты (комиссиясе) турында нигезләмә булу (әйе (күчермәсе комиссиягә бирелә) /юк) | |
| | Әйе | 3 |
| | Юк | 0 |
| | Үткәрелгән утырышлар һәм карап тикшерелгән мәсьәләләр саны | * |
| 2.7. | Хезмәтне саклау буенча вәкаләтле (ышанычлы) затлар булу (әйе (кеше) /юк) | |
| | 1 дән артык | 3 |
| | Юк | 0 |
| | Хезмәтне саклау буенча вәкаләтле (ышанычлы) затлар тарафыннан бирелгән күрсәтмәләр саны | * |
| | Күрсәтмәләрдә чагылдырылган кимчелекләрне бетерү % ы | * |
| 2.8. | Хезмәт шартларын яхшырту һәм сәламәтләндерү буенча чаралар планы булу (әйе (күчермәсе комиссиягә бирелә) /юк) | |
| | Әйе | 3 |
| | Юк | 0 |
| | Хезмәт шартларын яхшырту һәм сәламәтләндерү буенча чаралар планын үтәү % ы | * |
| | Хезмәт шартларын яхшырту һәм сәламәтләндерү буенча чаралар планын үтәүгә тотылган чыгымнар (мең сум) | * |
| 2.9. | Коллектив шартнамәсе (килешүе) булу (әйе (раслау датасы) /юк) | |
| | Әйе | 3 |
| | Юк | 0 |
| 2.10. | Коллектив шартнамәсендә (килешүендә) хезмәтне саклау буенча бүлек булу (әйе/юк) | |
| | Әйе | 3 |
| | Юк | 0 |
| | - планлаштырылган чараларның гомуми санына карата аның үтәлеш дәрәҗәсе, % ларда | * |
| 2.11. | Хезмәтне саклау буенча планлы чаралар үткәрү нәтиҗәсендә хезмәт шартлары яхшыртылган хезмәткәрләр саны, кеше | * |
| 2.12. | Хезмәтне саклауга тотылган чыгымнар суммасы, мең сум: | * |
| | - елына 1 хезмәткәргә исәбеннән, мең сум. | * |
| 2.13. | Продукция (эшләр, хезмәтләр) җитештерү чыгымнары суммасында хезмәтне саклау һәм хезмәт шартларын яхшырту чараларына тотылган чыгымнар өлеше | * |
| 2.14. | Сертификацияләнгән махсус өс киеме, махсус аяк киеме һәм башка индивидуаль саклану чаралары белән тәэмин ителеш, еллык ихтыяҗга карата % ларда | |
| | 80 % ка кадәр | 0 |
| | 80% тан 90% ка кадәр | 0,5 |
| | 90% тан 100% ка кадәр | 2 |
| 2.15. | Хезмәт шартлары буенча махсус бәяләү (аттестация) үткәрелгән оешмада махсус бәяләү (эш урыннарын аттестацияләү) үткәрүнең дәрәҗәсе, оешмадагы эш урыннарының гомуми санына карата % ларда | |
| | оешмадагы эш урыннарының гомуми санына карата % ларда | |
| | 50% тан ким | 0 |

| № т/б | Күрсәткечләр | Баллар саны |
|---|---|---|
| | 50% тан 80% ка кадәр | 2 |
| | 80% тан 100% ка кадәр | 5 |
| 2.16. | Хезмәткәрләрнең медицина каравы (тикшерүләре) үтү дәрәҗәсе, әлеге карауларны үтәргә тиешле хезмәткәрләр санына карата % ларда | |
| | 80% ка кадәр | 0 |
| | 80% тан 90% ка кадәр | 0,5 |
| | 90% тан югары | 3 |
| 2.17. | Хезмәтне саклау буенча җиһазланган кабинет (почмак(лар) булу (әйе/юк) | |
| | Әйе | 1 |
| | Юк | 0 |
| 2.18. | Хезмәтне саклау көннәре үткәрелде (үткәрелде (саны) /үткәрелмәде) | |
| | Үткәрелде (саны*) | 1 |
| | Үткәрелмәде | 0 |
| | 3. Производство травматизмы, һөнәргә бәйле авырулар, аварияләлек күрсәткечләре | |
| 3.1. | Производстводагы бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә зыян күрүчеләр саны, барлыгы, кеше, шул исәптән: | * |
| | - авырлык дәрәҗәсе буенча җиңел дип саналган бәхетсезлек очракларында | * |
| | - авыр бәхетсезлек очракларында, кеше | * |
| | - үлем белән тәмамланган бәхетсезлек очракларында, кеше | * |
| | - төркемле бәхетсезлек очракларында, кеше | * |
| 3.2. | Производстводагы бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә зыян күрүчеләр саны, 1 мең эшләүчегә исәпләгәндә (ешлык коэффициенты) | |
| | 4 кә кадәр | 3 |
| | 4 тән 6 га кадәр | 0.5 |
| | 6 дан югары | 0 |
| 3.3. | 1 һәм аннан күбрәк эш көне дәвамында хезмәткә яраклылыкны югалтып зыян күргәннәрнең хезмәткә яраксызлык көннәре саны, 1 зыян күрүче исәбеннән (авырлык коэффициенты) | |
| | 20 көнгә кадәр | 3 |
| | 20 дән 31 гә кадәр | 0.5 |
| | 31 дән югары | 0 |
| 3.4. | Беренче тапкыр һөнәргә бәйле авыру билгеләнгән затларның саны, барлыгы | |
| | 1 гә кадәр | 3 |
| | 1 дән 3 кә кадәр | 0 |
| | 3 тән югары | 0 |
| 3.5. | Куркыныч производство объектларындагы аварияләлек (әйе/юк) | |
| | Әйе | 0 |
| | Юк | 1 |
| 3.6. | Ведомстводагы автотранспортта аварияләлек дәрәҗәсе, автотранспорт чаралары берәмлеге исәбеннән | |
| | 0.5 кә кадәр | 1 |
| | 0.5 тән югары | 0 |

* - баллар тигез булганда һәм бәхәсле мәсьәләләрне хәл иткәндә комиссия тарафыннан исәпкә алына торган мәгълүматлар

Башкарма комитетның
2020 елның 30 ноябрендәге
6435 номерлы карарына
2 нче кушымта

Хезмәтне саклау буенча ел саен үткәрелә торган конкурсны үткәрү буенча комиссия составы

| № т/б | Ф.И.А.и. | Вазыйфа |
|---|---|---|
| 1. | Салахов Фәрид Шавкат улы | комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе |
| 2. | Мингалиев Рәүф Минрәхим улы | комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы |
| комиссия әгъзалары: | | |
| 3. | Апарина Марина Леонидовна | Татарстан Республикасы Хезмәт буенча дәүләт инспекциясенең Яр Чаллы шәһәре буенча бүлек башлыгы (килешенү буенча) |
| 4. | Гарипова Алена Наил кызы | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге баш белгече |
| 5. | Исхаков Илмир Зөфәр улы | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 6. | Кропотова Наталия Анатольевна | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 7. | Николаев Александр Николаевич | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсе җитәкчесе (килешенү буенча) |
| 8. | Нотфуллина Марина Авинировна | РФ Социаль иминият фондының ТР буенча ДУ РБ 9 нчы филиалының һөнәргә бәйле куркынычларны иминләштерү бүлеге башлыгы (килешенү буенча) |
| 9. | Хәлимов Рамил Мәрван улы | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе
урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе
башлыгы вазыйфаларын башкаручы А.Ф. Бареева